ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2021 п.г.т.Алексеевское № 490

**2022 елга Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Торак Кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен гражданнарның иң чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 15 декабрендәге ПУ-958 номерлы Указы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен тарифларны 2022 елга расларга:

- социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урынны карап торган өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урын күләме өчен (1 нче кушымта).

- дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү) (2 нче кушымта).

2. И.Ю. Мопинага «Таң» («Заря») район газетасына әлеге карарны бастырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 29 декабрендәге
490 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме**

| № | Хезмәтнең исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01. - 30.06. | 01.07. - 31.12. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 2,99 | 3,18 |
| 2 | Авыл яны территориясен санитар карап тору һәм санитар чистарту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 1,88 | 2,0 |
| 3 | Торак биналарны ремонтлау һәм йорт тирәсен төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 3,23 | 3,43 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт:<br>- йорт эчендәге санитар-техник челтәрләр<br>- җылылык челтәрләре | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 1,63<br>-| 1,73<br>- |
| 5 | Торак йортларда йорт эчендәге газ челтәрләренә һәм йорт эчендәге газ җиһазларына техник | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 0,35 | 0,40 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәт күрсәтү | | | |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 0,98 | 1,02 |

**Башкарма комитет эшләре идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 29 декабрендәге
490 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен (наем өчен түләү) күләме**

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтне үлчәү бердәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01. 30.06. | 01.07. 31.12. |
| Наемга | аена торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м | 6,11 | 6,73 |

**Башкарма комитет эшләре идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**